КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 587

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче; 2018 ел, 3 август, 631 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1152 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1227 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «сервитут» сүзеннән соң «, ачык сервитут» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «сервитут» сүзеннән соң «, ачык сервитут» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, урнаштыру тәртибендә һәм шартларында:

исемендә татар текстында «сервитут» сүзеннән соң «, ачык сервитут» сүзләрен өстәргә;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{36}$ статьясындагы 3 нче пункт нигезендә расланган объектларны (алга таба – объектлар) дәүләт милкендә яки муниципаль милектә бул-

ган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә (алга таба – җир кишәрлеге), җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыру процедураларын һәм шартларын регламентлаштыра.»;

2 пунктта:

татар текстында «сервитутлар» сүзеннән соң «, гавами сервитут» сүзләрен өстәргә;

«Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, 540 нчы боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторы нигезендә билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Объектларны урнаштыру җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган, яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итүгә вәкаләтле җирле орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан бирелә торган объектларны урнаштыруга рөхсәт нигезендә тормышка ашырыла.»;

икенче абзацта «, муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектларны урнаштыруга рөхсәт гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән срокка, әмма иң күбе биш елга бирелә.»;

4 пунктта:

икенче абзацта «стандарт булмаган» сүзләрен «стационар булмаган» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урнаштыру өчен төзелешенә рөхсәт кирәк булмаган гражданнар оборонасының саклау корылмалары, инженерлык саклау корылмалары;»;

9 пунктның «в» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органына» сүзләрен «вәкаләтле органга» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектларны урнаштыруга ризалыгы – объектларны урнаштыру федераль милектә яки Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылган очракта;»;

14 пунктта:

«в» пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) объектларны урнаштыру өчен планлаштырыла торган җир кишәрлегенә карата вәкаләтле органга милекче хокукларын гамәлгә ашыру хокукы бирелмәсә йә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләре бирелмәсә;»;

«д» пунктчасында «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, 540 нчы боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләрен

рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторы нигезендә билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

19 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Объектларны гражданнарга һәм юридик затларга бирелмәгән яисә дәүләт, муниципаль предприятиеләргә яки дәүләт, муниципаль учреждениеләргә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнаштыруга рөхсәт бирү җир кишәрлекләре милекчесе хокукларын гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителгән булса, объектларны урнаштыру өчен түләү Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына керә.»;

20 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуга карата гариза бирүче тарафыннан вәкаләтле орган төзегән ведомствоара комиссиягә шикаять бирелергә мөмкин.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче; 2017 ел, 6 март, 130 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 439 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 950 нче; 2018 ел, 14 март, 151 нче; 2018 ел, 11 июнь, 461 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1139 нчы; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 2 июль, 525 нче; 2019 ел, 30 август, 735 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 859 нчы; 2020 ел, 28 гыйнвар, 31 нче; 2020 ел, 25 февраль, 141 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 830 нчы, 2020 ел, 10 ноябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 15 июнь, 455 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2.9 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.102 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.102. Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, ачык сервитут билгеләмичә урнаштыруга рөхсәт бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин